| МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

31.12.2013 № 02-146

Казан ш.

«Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет росписен һәм Татарстан Республикасы бюджет средстволарын баш бүлүчеләрнең (Татарстан Республикасы бюджет дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторларының) бюджет росписьләрен төзү һәм алып бару тәртибен раслау турында» 02.04.2010 ел, №02-29 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Бюджет процессын камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым законнар актларына үзгәрешләр кертү турында» 07.05.2013 ел, №104-ФЗ Федераль закон һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым законнар актларына үзгәрешләр кертү турында» 16.10.2013 ел, №79-ТРЗ Ттатарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

1. «Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет росписен һәм Татарстан Республикасы бюджет средстволарын баш бүлүчеләрнең (Татарстан Республикасы бюджет дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторларының) бюджет росписьләрен төзү һәм алып бару тәртибен раслау турында» 02.04.2010 ел, №02-29 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 30.12.2010 ел, №02-125, 29.04.2011 ел, №02-44, 23.12.2011 ел, №02-130 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

$2^1$ пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет росписен һәм Татарстан Республикасы бюджет средстволарын баш бүлүчеләрнең (Татарстан Республикасы бюджет дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторларының) бюджет росписьләрен төзү һәм алып бару тәртибендә:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җыелма бюджет росписе үз эченә ала:

1) Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүчеләр, бюджетлар чыгымнары классификациясе, дәүләт идарәсе секторы операцияләре классификациясе чыгымнарының төркемен, төркемчәсен, элементларын үз эченә алган чыгымнар бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төрләре (алга таба – чыгымнар төрләре) буенча агымдагы финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы бюджет чыгымнары буенча бюджет ассигнованиеләре;

2) бюджетлар дефицитларын финанслау чыганакларының классификациясе кодлары буенча агымдагы финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы бюджет чыгымнары буенча бюджет ассигнованиеләре, Татарстан Республикасы бюджет средстволары учеты буенча бердәм счеттагы средстволар калдыклары белән идарә итү операцияләреннән тыш.»;

б) түбәндәге эчтәлектәге $1^1$ пунктын өстәргә:

« $1^1$. Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының аналитик учетын алып бару һәм аныклау максатыннан чыгып, түбәндәге классификация төрләре кулланыла:

өстәмә функциональ код;

өстәмә икътисадый код;

өстәмә чыгымнар коды.».

в) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүчеләргә (алга таба - баш бүлүчеләр) бюджет йөкләмәләре лимитлары Татарстан Республикасы бюджеты средстволарын баш бүлүчеләр, бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре, дәүләт идарәсе секторының операцияләр классификациясе чыгымнары кодлары буенча раслана.»;

г) 12.1 пунктта «җыелма бюджет росписен һәм бюджет йөкләмәләре лимитларын үзгәртү турында белешмәләрне кушымта итеп» дигән сүзләрне «өстәмә классификация кодлары буенча җыелма бюджет росписен һәм бюджет

йөкләмәләре лимитларын һәм расшифровкаларны үзгәртү турында белешмәләрне кушымта итеп» дигән сүзләр өстәргә;

д) 13.1 пунктта «бюджет учреждениеләре» дигән сүзләрне «казна учреждениеләре» дигән сүзләргә алыштырырга;

е) 13.3 пунктны үз көчен югалткан дип санарга;

ж) 13.5 пунктта «(муниципаль)» дигән сүзне төшереп калдырырга;

з) 14 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) баш бүлүчеләрнең (алар карамагындагы казна учреждениеләренең) составы яки вәкаләтләре үзгәрү);»;

и) №2 һәм №3 кушымталарны бу Боерыкка №1 һәм №2 кушымталарга туры китереп бәян итәргә;

к) 10 кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет росписен һәм Татарстан Республикасы бюджет средстволарын баш бүлүчеләрнең (Татарстан Республикасы бюджет дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторларының) бюджет росписьләрен төзү һәм алып бару тәртибен раслау турында» 02.04.2010 ел, №02-29 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 29.04.2011 ел, №02-44 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу Боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. Бу Боерык 2014 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Министр Р.Р. Гайзатуллин

Татарстан Республикасы Финанс
министрлыгының 31.12.2013 ел,
№02-146 боерыгына
№1 кушымта

«02.04.2010 ел, №02-29 Татарстан Республикасы
бюджетының җыелма бюджет росписен  һәм
Татарстан Республикасы бюджет средстволарын
баш бүлүчеләрнең  (Татарстан Республикасы бюджет
дефицитын финанслау чыганакларының баш
администраторларының) бюджет росписьләрен
төзү һәм алып бару тәртибенә №2 кушымта

**20___ финанс елына**
**һәм планда каралган**
**20___ и 20____ еллар чорына бюджет ассигнованиеләре турында**
**Уведомление**

Татарстан Республикасы бюджет средсттволарын баш бүлүче: ________________________________

Үлчәү берәмлеге: сум.

Нигез: ________________________________
(закон, указ, карар, боерык, хат)

| Бюджет классификациясе | | | | | | Ассигнованиеләр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Коды | | | | | | агымдагы 20____ елга | планда каралган чорның I елына | планда каралган чорның II елына |
| баш бүлүчене ң | бүле кнең | бүлекчә нең | максатч ан статьяс ының | чыгым төренең | дәүләт идарәсе секторы операциясенең | | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| Барлыгы | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы финанс министры ________________ ________________________________ »
(имза) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 31.12.2013 ел, №02-146 боерыгына
№2 кушымта

«02.04.2010 ел, №02-29 Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет росписен һәм Татарстан Республикасы бюджет средстволарын баш бүлүчеләрнең (Татарстан Республикасы бюджет дефицитын финанслау чыганакларының баш администраторларының) бюджет росписьләрен төзү һәм алып бару тәртибенә №3 кушымта

**20___ финанс елына һәм**
**планда каралган 20____ һәм 20____ еллар чорына бюджет йөкләмәләре лимитлары турында**
**Уведомление**

Татарстан Республикасы бюджет средсттволарын баш бүлүче: ____________________________________________

Үлчәү берәмлеге: сум.

Нигез: ____________________________________________
(закон, указ, карар, боерык, хат)

| Бюджет классификациясе | | | | | | Лимитлар | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Коды | | | | | | агымдагы 20____ елга | планда каралган чорның I елына | планда каралган чорның II елына | |
| баш бүлүчене ң | бүле кнең | бүлекчә нең | максатч ан статьяс ының | чыгым төренең | дәүләт идарәсе секторы операциясенең | | | | |
| | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |
| Барлыгы | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы финанс министры ______________ (имза) ______________________________ (тулы имза) »